Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы
Карары

2018 ел, 14 нче февраль № 98

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Иске Казиле авыл
җирлеге Советының 2017 елның 29
декабрендәге “Иске Казиле авыл җирлеге
Советы депутаты статусы турында”гы
Нигезләмә хакында” 65нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 декабрендәге 65нче номерлы карары белән расланган Иске Казиле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын «сәяси партиядә,» сүзеннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюзда,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы рәисе И.Х. Сәгдиев